**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БОЛГАР ШЭhЭРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

---

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 34 «15» 04 2022 ел

Шәһәр Башкарма комитетының 2021 елның 2 июлендәге 50 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны торак бина, торак урыны, күп фатирлы йортның яшәү өчен яраксыз һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле торак йортны, бакча йортын һәм бакча йортын торак йорты дип тану турындагы Нигезләмәнең 61 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 17 февралендәге 187 номерлы карары нигезендә, Болгар шәһәр Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Шәһәр Башкарма комитетының 2021 елның 2 июлендәге 50 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү:

1.1. 2.8.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) су басу, су басу зонасы чикләрендә урнашкан жир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турындагы гаризаны караганда);».

1.2. 2.8.2 пунктының 7 пунктчасын 8 пункт дип санарга.

2. 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәжбүри булган хезмәтләр исемлеге оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан күрсәтелә».

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны үземдә калдырам.

Болгар шәһәр Башкарма комитеты житәкчесе А.В.Костина